**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«24» октябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогы гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегенең Красномайский поселогы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, аларның тол калган хатыннарыннан, 1 төркем инвалидларыннан тыш 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту»

Халык җыенында рәислек итүче: В.И. Гаврилов

Тимерлек авыл җирлеге башлыгы В.И. Гаврилов